<table>
<tr><td>СОВЕТ<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН</td><td>ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ</td></tr>
</table>

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30 декабря 2025 г. с.Шалты № 15

Баулы муниципаль районы авыл җирлеге
җирле үзидарә органнарының җирлек торак
пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге
автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге
буенча вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә
ашыруны Баулы муниципаль районы җирле
үзидарә органнарына гомуми файдаланудагы
җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлеген
раслау өлешендә тапшыру турында

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясындагы 9 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 3 өлешенең 17 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Шалты авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының җирлек пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге буенча вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлеген раслау өлешендә Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшырырга.

2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советына тәкъдим итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итү турындагы мәсьәләне карарга;

Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының җирлек пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге буенча вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны кабул итү-тапшыру турында гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлеген раслау өлешендә Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарына килешүләр төзергә.

3. Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының җирлек пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге буенча вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны кабул итү-тапшыру турындагы килешүләр гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлеген раслау өлешендә рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артымнан калдырам.

Баулы муниципаль районы
Шалты авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе З.Х. Фаткуллин